# Т.ГЫЙЗЗӘТ БЕЛӘН С.СӘЙДӘШЕВНЕҢ ИҖАТ ДУСЛЫГЫ[1]

1920 елларда Татар дәүләт театры спектакльләрендә музыка киң урын алды. Бу хәл исә татар музыка культурасын үстерүдә зур роль уйнады. Чөнки музыкаль спектакльләр тирәсендә җырчылар, музыкантлар туплана барды, оркестр барлыкка килде, яшь композиторлар үсеп чыкты, опера һәм музыкаль драма әсәрләре языла башлады. Шундый яңа жанрларның берсе Таҗи Гыйззәтнең 1928 елда куелган «Наемщик» драмасы булды. Бу әсәр, беренчедән, 1923–1926 елларда куелган «Талир тәңкә» драмасыннан соң Т.Гыйззәтнең үткен каләмле һәм тирән фикерле драматург булып җитлегүен раслаcа, икенчедән, С.Сәйдәшевнең киң диапазонлы талант иясе булуын күрсәтте. Һәм шушы спектакльдән соң инде Таҗи Гыйззәт белән Салих Сәйдәшевнең иҗат дуслыклары егерме биш ел буе, гомерләренең ахыр көннәренә кадәр дәвам итте.

*С.Сәйдәшев музеенда сөекле композиторыбызның классик драматург Т.Гыйззәт белән иҗади дуслыгына багышланган кичәдә*



[1] Сәлимҗанов Х. Артист язмалары. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997. 163–170 б.



*Казбек Гыйззәтов Т.Гыйззәт һәм С.Сәйдәшев каберләре янында*

«Наемщик» спектаклендәге уннарча музыкаль номерлар – дуэт, хор, симфоник оркестр өчен язылган марш, кереш өлеш (увертюра) һәм бию көйләре, бигрәк тә масса җырлары, Батырҗан һәм Гөлйөзем арияләре спектакльнең идея-эмоциональ көчен тирәнрәк ачарга ярдәм иттеләр.

Салих Сәйдәшев музыкасында халыкның кайгы-хәсрәте, изүчеләргә каршы көрәшкә омтылулары чагыла, шул ук вакытта ул гади халыкның оптимизмын да, мәхәббәтен дә һәм хөр күңеллелеген дә тасвирлый. Менә шуның өчен дә «Наемщик» драмасының сюжеты, вакыйгалар агышы үзенең бөтен кирәклеге белән тамашачы күңелендә онытылмас хатирә булып калды.

...Бөек Октябрь социалистик революциясенең егерме еллык бәйрәмен театр Таҗи Гыйззәтнең оста каләмле чын драматург булуын күрсәтте. Һәм, гомумән, бу елларда ул Татар дәүләт академия театры репертуарының үзәген тәшкил итте.

Мәсәлән, 1934–1935 елларда аның «Чаткылар» әсәре куелды. Бу әсәр 1923 һәм 1926 елларда «Талир тәңкә» исеме белән уйналды. Ул вакытта аның күләме дә кеч-

кенә иде. Соңгы вариантта бер зур пәрдә, ягъни Сабир өе яңадан язылып, хәзер инде ул зур полотнодагы әсәргә әверелгән иде. Шулай ук әсәрдә яңа образ, социал-демократлар партиясе вәкиле Орлов һ.б. образлар өстәлгән, элек булган образлар да шактый тулыландырылган иде. Бу спектакльдә Хәлил Әбҗәлилов – староста, Галия Булатова – Маһи, Габдулла Уральский – Тимай, аеруча Рамай ролендә яшь артист Бәкер Йосыпов онытылмаслык образлар тудырдылар (Хәким ага үзе төп рольләрнең берсе булган Гаяз ролен уйный иде. – *К.Г.*).

Драматургның «Мактаулы заман» пьесасы гаять зур тантана белән үтте. 1936 елгы сезонның иң уңышлы спектакльләреннән булды ул. Ул үзе дә бу спектакльдә Ярул бабай ролен яратып уйнады. Ә инде үзенең яраткан образларын: Ногманны – Бәкер Йосыпов, Хөбәйбәне – Нәгыймә Таждарова, Җансатаровны – Зариф Закиров, Майбәдәрне – Гөлсем Камская, Фәтхияне – Мәрзия Миңлебаевалар уйнаган көнне гаять дәрәҗәдә шат-күңелле була иде. Алар сәхнәдә вакытта Т.Гыйззәт, һәрвакыт кулисага яшеренеп, авызын ачып, сакалын селкетеп, рәхәтләнеп карап тора иде. Ә менә, кызганычка каршы, театрда бу әсәрнең икенче куелышы (1954 елның көзендә, режиссер Равил Тумашев постановкасы) авторның кәефен бөтенләй бозды. Кешеләрнең характерын ачу, образларга дөрес трактовка бирү урынына сәхнәдә иләмсез сыерлар, үгезләр мөгрәү тавышлары өстенлек алды. Абзар янына бер-ике йөк чын тирес тә өеп куйсаң, бөтенләй сыер абзары күренеше була иде. Монысында аның беренче куелышының эзе дә калмады. Таҗи абый бу уңышсызлыкны бик авыр кичерде. Режиссер белән сөйләшергә дә теләмәде.

Көннәрнең берендә Таҗи абый мәрхүм мине өенә чакырып бик каты ачуланды. «Сез, олы артистлар, эшнең барып чыкмаячагын күрә торып әйтмәгәнсез, – дип әрләп алды. – Аңлы рәвештә минем иң яраткан әсәремне провалить иттегез», – дип, мине, Сарымсаковны, Уразиковны суганлы-борычлы сүзләр белән сыйлады. Димәк, әгәр дә режиссер әсәрдән образларны дөрес аңлап, аның төп идеясен ача алмаса, нинди генә талантлы артистлар уйнаса да, спектакль уңыш казана алмый дигән сүз.

Драма жанрында эшләү белән бергә, Т.Гыйззәт бу елларда (1935–1940. – *К.Г.*) комедия өлкәсендә дә каләм тибрәтә башлады. Шундыйларның берсе иске мәдрәсә тормышыннан алып язылган «Кыю кызлар» әсәре булды.

«Кыю кызлар» спектаклен Мәскәү белгечләре караганнан соң, шуларның берсе әлеге әсәрдән Байтирәк персонажын француз драматургы Бомаршеның Фигаро образына тиңләп әйткән иде (Байтирәк ролен ул елларда бик оста итеп Хәким абый Сәлимҗанов башкарды. – *К.Г.*).

«Кыю кызлар» комедиясе белән Таҗи Гыйззәт үзен киң колачлы, зур эрудицияле әдип итеп күрсәтте.

«Ташкыннар» драмасы татар крестьянының революциягә килүен һәм аңлы рәвештә көрәш сафына басуын гәүдәләндергән беренче әсәр иде. Шуның өчен дә театр аңа бик зур игътибар бирде.

Режиссер Гомәр Исмәгыйлев әсәрнең идея эчтәлеген һәм образларның характер үзенчәлекләрен тирәнтен аңлап эш итте. Ул беренче чиратта төп игътибарны төрле катлам вәкилләренең эчке кичерешләренә, революция дулкынында чайкалып, үз урынын таба алмаган авыл крестьянының рухи үсешен чагылдыруга юнәлдерде. Шуның нәтиҗәсендә әсәрнең рухын тәшкил итүче Биктимер һәм аның семьясындагы кешеләрнең үз кичерешләре, дөньяга карашларындагы үзгәрешләре нечкә психологик планда күрсәтелде һәм алар әсәрнең үзәген тәшкил иттеләр.

Бу, беренчедән, реализмның тирәнлеге, образларның бөтенлеге, конфликтларның үзенчәлекле булуы белән Т.Гыйззәт иҗатының чәчәк атуын исбатласа, икенчедән, Г.Исмәгыйлевнең киң колачлы һәм тирән фикер йөртүче режиссер булуын күрсәтте. Ләкин спектакль генеральный репетиция хәленә килеп җиткәч, шәхес культы шаукымы нәтиҗәсендә Г.Исмәгыйлев театрдан китәргә мәҗбүр булды (Хәким абый барысын да әйтеп бетермәгән. «Шәхес культы шаукымы» дип әйтү Исмәгыйлевнең театрдан китүенең сәбәбен ачык калдыра әле. Асылда, хикмәт шунда ки, нәкъ генераль репетиция вакыты килеп җиткәч, ниндидер яхшылык теләүче кеше

Исмәгыйлевкә «сине арестка алырга җыеналар» дип әйтә. Шуннан Гомәр ага, күп уйлап тормыйча, семьясын Казанда калдырып, Урта Азия якларына китә. – *К.Г.*). Спектакльне режиссерлар коллегиясе – Ширияздан Сарымсаков, Хөсәен Уразиков һәм мин – дөньяга чыгардык...

«Ташкыннар» спектакле театрда үзенә бер эпохаль төс алды. Ул авторның гына түгел, бәлки Татар дәүләт академия театры коллективының зур иҗат бәйрәме булды.

...1935–1940 елларда Таҗи Гыйззәт гаҗәеп киеренке рәвештә иҗат итте. «Ташкыннар» спектакле тантанасы сүрелергә дә өлгермәде, ул үзенең «Бишбүләк» әсәрен язып бетерде. Бу пьеса Таҗи Гыйззәтнең драматургик мастерлыгын һәм аның авыл тормышын, төрле катлау вәкилләренең характерларын, психологияләренең яхшы белүен раслады. Әсәрне сәхнәләштерүдә режиссер Вәлиев-Сульва һәм автор үзе гаять күп көч куйдылар. Шулай ук художник Мортаза Абдуллинның саф реалистик планда эшләнгән оформлениесе дә спектакльнең отышлы булуына зур ярдәм итте. Ә инде Салих Сәйдәшевнең сокландыргыч гүзәл мелодияләре спектакльнең уңышын бермә-бер арттыра төште. Ул кыска гына вакыт эчендә илле тапкыр уйналды һәм озын гомерле спектакльләр өчен көрәш башлап җибәрде.

«Бишбүләк»нең беренче постановкасы артистлар өчен дә зур уңыш китерде. Бу шулай булырга тиеш тә. Чөнки спектакльнең идея эчтәлеге, аның төп характеры дөрес ачыла икән, димәк, образлар да дөрес трактовать ителә дигән сүз...

**Чыганак:** *Таҗи Гыйззәт: истәлекләр, мәкаләләр / авт.-төз. К. Гыйззәтов.- Казан: Татар.кит.нәшр., 2010.- 151 б.*